**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1037**
**19.02.2024**

Башкарма комитетның 2020 елның 15 июнендәге 2848 номерлы Карары белән расланган «2020-2025 елларга «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2023 елның 29 декабрендәге 2386 номерлы Карары, шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2020 елның 15 июнендәге 2848 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2020 елның 23 июнендәге 2997 номерлы, 2021 елның 20 октябрендәге 6902 номерлы, 2021 елның 13 декабрендәге 8098 номерлы, 2023 елның 2 июнендәге 4673 номерлы Карарлары редакциясендә) расланган «2020-2025 елларга «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасына, 4 бүлекнең 19 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«7) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртип һәм күләм нигезендә һәм Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа (алга таба – ЕЦП) операторлары билгеләгән форматларга туры китереп, ЕЦПда торак шартларын яхшырту өчен яшь гаиләләргә бирелә торган социаль түләүләр турында мәгълүмат урнаштыруны тәэмин итү;».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы А.Н. Лашинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов